РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
19.05.2020

**КАРАР**
№ 238

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр күләмен билгеләү һәм бирү тәртибен раслау турында»гы 2018 елның 20 июнендәге 263 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында»гы 2017 елның 7 маендагы 541 номерлы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр күләмен билгеләү һәм бирү тәртибен раслау турында»гы 2018 елның 20 июнендәге 263 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 6 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел (мондый таләпләр хокукый актта каралган очракта);».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми

порталында урнаштырырга» (PRAVO.TATARSTAN.RU.).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Хисамовага йөкләргә.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**